РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» 02 2021 г. №69

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 16 сентябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 512 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 16 сентябрендәге 512 номерлы карары белән расланган “Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балаларга

компенсация түләүләре бирү Тәртибе”нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Компенсация алу өчен мөрәҗәгать итүчегә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенә (алга таба - вәкаләтле орган) түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

a) компенсация билгеләү турында гариза;

b) өстәмә компенсация бирү турында гариза бирелгән айга кадәр булган өч айга гаиләнең һәр әгъзасы керемнәре турында документлар;

c) компенсация билгеләнә торган баланың туу турында таныклыгы күчермәсен (оригиналны күрсәтеп, әгәр күчермә нотариаль таныкланмаган булса);

d) мөрәҗәгать итүче (күчермәсе нотариаль таныкланмаган булса, төп нөсхәсен күрсәтеп) анасы, атасы (законлы вәкиле) булып торучы башка балаларның туу (уллыкка алу) турында таныклык күчермәләре. Опекадагы балага компенсация билгеләү өчен өстәмә рәвештә балага опека билгеләнүе турында җирле үзидарә органнары карарыннан өземтә тапшырыла;

e) Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычлы затлар өчен ышанычнамә күчермәсе;

f) ата яки ананың берсенең (ата-ананың) бала (балалар) мөнәсәбәтендә ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән булуы очрагында, суд карары;

g) баланы тиешле белем бирү оешмасына урнаштыру турындагы шартнамәнең күчермәсе;

h) белем бирү оешмасында баланы карап тоткан һәм тәрбияләгән өчен түләү квитанциясе күчермәсе;

i) гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан яисә аларның законлы вәкилләреннән ирекле формада түбәндәгеләрне раслаучы документлар:

j) аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булу;

k) шәхси мәгълүматны органга яисә оешмага тапшырганда мөрәҗәгать итүченең аларның исеменнән эш итәргә вәкаләте;

l) Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнары нигезендә, мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау турында белешмә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе С.П. Самонина

Р. М. Якупов
2-74-14